| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.07.2018_** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1469** |

Күп фатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында

2009 елның 23 сентябрендәге 2088 номерлы карарындагы үзгәрешләре белән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән 2018 елның 22 июненедәге 258 номерлы, 259 номерлы, 260 номерлы, 261 номерлы,262 номерлы, 263 номерлы ведомствоара комиссияләрнең актлары һәм бәяләмәләрен исәпкә алып, , шулай ук ТР Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., торак йортның Төзүчеләр ур., 8 нче йорт, ТР ЗМР Зеленодольск районы, торак йортның Новониколаевский пос., Төзүчеләр ур., 35 нче йорт, ТР ЗМР Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., торак йортның Төзүчеләр ур., 36 нчы йорт ТР ЗМР Новониколаевский п., торак йортның Солидарная урамындагы, 28 нче йорт, ТР ЗМР Новониколаевский п., торак йортның Солидарная урамындагы, 32 нче йорт, Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., торак йортның Каен ур., 12 нче йорт буенча төзекләндерергә һәм сүтелргә тиешле объектларга техник тикшерү нәтиҗәләре белән, РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбәндәге адреслар буенча күп фатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танырга:
   - Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., Төзүчеләр ур., 8 нче йорт;
   - Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., Төзүчеләр ур., 35 нче йорт;
   - Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., Төзүчеләр ур., 36 нчы йорт;
   - Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., Солидарная ур., 28 нче йорт;
   - Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., Солидарная ур., 32 нче йорт;
   - Зеленодольск районы, Новониколаевский пос., Каен ур., 12 нче йорт.
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

-кулланыштан алынган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләренә;

- «Торак сәясәте департаменты»МКУ.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников